КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 26 август г.Казань № 744

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 нчы июль, 325 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 325 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 ел, 24 февраль, 101 нче; 2009 ел, 9 ноябрь, 776 нчы; 2010 ел, 9 апрель, 253 нче; 2010 ел, 9 июнь, 454 нче; 2010 ел, 10 декабрь, 1038 нче; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 21 февраль, 125 нче; 2011 ел, 25 март, 220 нче; 2011 ел, 13 апрель, 291 нче; 2011 ел, 29 июль, 613 нче; 2011 ел, 13 август, 674 нче; 2012 ел, 8 июнь, 494 нче; 2012 ел, 30 июль, 646 нчы; 2013 ел, 9 февраль, 80 нче; 2013 ел, 14 март, 163 нче; 2013 ел, 7 октябрь, 730 нчы; 2013 ел, 30 ноябрь, 940 нчы; 2014 ел, 5 февраль, 64 нче; 2014 ел, 29 март, 201 нче; 2014 ел, 11 ноябрь, 853 нче; 2015 ел, 2 февраль, 49 нчы; 2015 ел, 3 июнь, 401 нче; 2015 ел, 20 август, 610 нчы; 2015 ел, 2 октябрь, 733 нче; 2016 ел, 26 февраль, 121 нче; 2016 ел, 25 ноябрь, 874 нче; 2017 ел, 9 февраль, 74 нче; 2017 ел, 10 июль, 468 нче; 2017 ел, 6 ноябрь, 846 нчы; 2017 ел, 30 ноябрь, 930 нчы; 2018 ел, 29 март, 185 нче; 2018 ел, 4 май, 317 нче; 2018 ел, 27 июнь, 523 нче; 2018 ел, 15 декабрь,

1140 нчы; 2019 ел, 16 гыйнвар, 9 нчы; 2019 ел, 4 апрель, 270 нче; 2019 ел, 29 сентябрь, 860 нчы; 2020 ел, 26 март, 220 нче; 2020 ел, 21 апрель, 311 нче, 2020 ел, 25 май, 424 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Министрлык түбәндәге төп функцияләрне гамәлгә ашыру өчен җаваплы:

табигый ресурслардан файдалану, әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә идарә итү (01.06), шул исәптән:

атмосфера һавасын саклау өлкәсендә идарә итү (01.06.06*);

радиацион куркынычсызлыкны тәэмин итү (01.06.08*);

вәкаләтләр чикләрендә Татарстан Республикасында радиацион хәлне тикшереп тору (01.06.16*);

җир асты байлыкларыннан файдалану мөнәсәбәтләре өлкәсендә җайга салу (01.06.01*), шул исәптән:

файдалануга бирелә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләре турында файдалы казылма запасларына, геологик, экономик һәм экологик белешмәләргә дәүләт экспертизасы үткәрүне оештыру (01.06.15*);

Татарстан Республикасы территориясендә геологик разведка һәм геодезия эшчәнлеге белән идарә итү (03.01.09*);

хуҗалык һәм башка төр эшчәнлекне тормышка ашырганда төбәк дәүләт экология күзәтчелеге, федераль дәүләт экологик күзәтчелегенә караган объектлардан файдаланып эшчәнлектән тыш (01.06.11), түбәндәге юнәлешләр буенча:

федераль дәүләт күзәтчелегенә караган су объектларыннан тыш, су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә, шулай ук төбәк дәүләт күзәтчелегенә караган су объектларында урнашкан гидроэнергетика объектларының саклау зоналары чикләрендә судан файдалануның һәм яр буе полосасы участокларыннан (шул исәптән гидроэнергетика объектларына кушылу участокларыннан) файдалануның махсус шартларын үтәүгә төбәк дәүләт күзәтчелеге (01.06.11.01*);

төбәк дәүләт экология күзәтчелегенә караган хуҗалык һәм башка эшчәнлек объектларында атмосфера һавасын саклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеге (01.06.11.02*);

төбәк дәүләт экология күзәтчелегенә караган хуҗалык һәм башка эшчәнлек объектларында калдыклар белән эш итү өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеге (01.06.11.03*);

җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләренә карата җир асты байлыкларын геологик өйрәнүгә, рациональ файдалануга һәм саклауга төбәк дәүләт күзәтчелеге (01.06.11.04*);

---

*Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары функцияләре кодификаторын раслау турында» 2006 ел, 2 май, 220 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары функцияләре кодификаторы буенча кодны билгеләү.

үзәкләштерелгән ташландык суларны агызу системасы аша юынтык суларны агызуга төбәк дүләт экология күзәтчелеге (01.06.11.05*);

төбәк дәүләт экология күзәтчелегенә караган объектларда хуҗалык һәм башка төр эшчәнлекне тормышка ашырганда экологик экспертиза турындагы законнарның үтәлешен контрольдә тоту.»;

3.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2. Министрлык үз компетенциясе кысаларында түбәндәгеләр белән хезмәттәшлек итә:

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән дәүләт финанслары белән идарә итү функциясен тормышка ашырганда (01.02*);

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы белән юстиция өлкәсендә идарә функцияләрен гамәлгә ашырганда (01.03*);

Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы белән Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системаларын үстерү белән идарә итү функциясен тормышка ашырганда (дәүләт мәгълүмат ресурсларын формалаштыру белән идарә итүдән тыш) (01.15.02*);

Татарстан РеспубликасыТөзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы белән территориаль планлаштыру функцияләрен тормышка ашырганда (01.05.01*);

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы белән гражданнар оборонасы, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә идарә функцияләрен тормышка ашырганда (02.01*);

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы белән Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәт һәм җир ресурслары белән идарә итү функциясен тормышка ашырганда (01.07*);

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы белән хезмәт белән идарә итү функцияләрен тормышка ашырганда (01.13*);

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

социаль-икътисадый программалаштыру (01.01*);

инвестиция эшчәнлеге өлкәсендә җайга салу (01.09*);

инновацион эшчәнлекне үстерү белән идарә итү (01.11*);

Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат ресурсларын формалаштыру белән идарә итү (01.15.01*);

Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы белән сәнәгать белән идарә итү функцияләрен тормышка ашырганда (03.01*);

Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты белән социаль-икътисадый мониторинг нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат ресурсларын формалаштыру буенча идарә функциясен тормышка ашырганда (01.15.01.1*);

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты белән архив эше белән идарә итү функциясен тормышка ашырганда (01.17*).»;

3.3 пунктының 3.3.11 пунктчасында:

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«файдалы казылма һәм җир асты сулары запасларына, файдалануга бирелә торган җир асты байлыклары участоклары турында геологик белешмәләргә дәүләт экспертизасында катнаша;»;

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«файдалы казылма һәм җир асты сулары запасларына, файдалануга бирелә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләренә, шулай ук эчәргә яраклы су белән тәэмин итү яки техник су белән тәэмин итү максатларында файдаланыла торган һәм чыгару күләме тәүлегенә 500 куб.метрдан артмаган файдалы казылма запасларына геологик белешмәләргә дәүләт экспертизасы үткәрүне оештыра;».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А. В. Песошин